Министерство образования и науки Республики Татарстан
Государственное автономное профессиональное образовательное учреждение
«ЕЛАБУЖСКИЙ ПОЛИТЕХНИЧЕСКИЙ КОЛЛЕДЖ»

Рассмотрено
на заседании ЦМК ОУД,
ОГСЭ
____________
В.Г. Романова
«28» августа 2022г.

Рассмотрено и принято на
Педагогическом совете
Протокол № 1 от 29.08 2022г.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА УЧЕБНОЙ ДИСЦИПЛИНЫ

## ОУД.12 РОДНАЯ ЛИТЕРАТУРА

для специальности СПО:

**15.01.05 Сварщик (ручной и частичной механизированной сварки (наплавки)**

**группа 231**

2022 г.

Татар әдәбияты (Родная литература) укыту фәне буенча төзелгән эш программасы түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп эшләнде:
1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең федераль Законы (29.12.2012 №273-ФЗ);
2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы (гамәлдәге редакциядә);
3. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 нче ел, 1нче июль)
4. Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (X-XI сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа, Казан китап нәшрияты, 2013 нче ел.

15.01.05.Эретеп ябыштыручы (кул белән һәм өлешчә механикалаштырылган эретеп ябыштыру (эретелмәләр) белгечлеге буенча (РФ Мәгариф һәм Фән министрлыгының 2016 елның 9 декабрендә 1547нче номерлы боерыгы белән расланган) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Алабуга политехник көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең 2022-2023 нче уку елына укыту планы

Татар әдәбияты (Родная литература) укыту фәне буенча гомуми белем бирүнең эш программасы төп гомуми белем нигезендә Урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри программасы белән беррәттән, урта гомуми белем бирүгә тәгаенләнгән. Программа урта гомуми бирү ФДБС таләпләрен истә тотып төзелде (РФ Мәгариф һәм Фән министрлыгының 2012 елның 17 маенда 413нче боерыгы белән расланган).

**Программа түбәндәге таләпләрне истә тота:**
-Россия Федерациясе Мәгариф һәм Фән министрлыгының 2012 нче елның 17 нче маенда 413 нче номерлы боерыгы белән расланган урта гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем стандарты;
- 15.01.05.Эретеп ябыштыручы (кул белән һәм өлешчә механикалаштырылган эретеп ябыштыру (эретелмәләр) белгечлеге буенча Россия Федерациясе Мәгариф һәм Фән министрлыгының 2016 нчы елның 9 нчы декабрендә 1547 нче номерлы боерыгы белән расланган Урта һөнәри белем бирүнең Федераль дәүләт белем стандарты ;
-“Россия Федерациясенең мәгарифе турында”гы федераль Законга тәрбия мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында” 2020нче елның 31июлендә 304-ФЗ номеры белән теркәлгән Федераль законы;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм Фән министрлыгының 441 нче номеры белән 2020 нче елның 28 нче августында теркәлгән боерыгы “Россия Федерациясе Мәгариф һәм Фән министрлыгының 464 нче номеры белән 2013 нче елның 14 нче июнендә теркәлгән боерыгы “Урта һөнәри белем бирүдә белем бирү программалары буенча эшчәнлекне оештыру һәм тормышка ашыру”.

**Төзүче оешма:** Урта һөнәри белем «Алабуга политехник көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем учреждениясе

**Төзүче:**
Мөхәмәдеева Рәмзия Мәкмүн кызы, укытучы

**Эчтәлек**

1. Уку фәненең эш программасы паспорты. 4
2. Уку фәненең эчтәлеге. 7
3. Уку фәнен тормышка ашыру шартлары. 14
4. Уку фәнен үзләштерүне тикшерү һәм бәяләү. 15

## 1. Уку фәненең эш программасы паспорты
## <u>ОУД.11 Татар әдәбияты</u>

**1.1.Программаның куллану өлкәсе**

Татар әдәбиятының эш программасы урта һөнәри белем бирүнең техник һәм социаль - икътисади юнәлештәге 15.01.05.Эретеп ябыштыручы (кул белән һәм өлешчә механикалаштырылган эретеп ябыштыру (эретелмәләр) белгечлеге өчен төзелде._Базис укыту планы белән эшләүче урта һөнәри белем бирүче «Алабуга политехник көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем учреждениясендә татар әдәбиятын укыту программасы 4 бүлектән тора: уку фәненең эш программасының паспорты, уку фәненең төзелеше һәм эчтәлеге, уку фәнен тормышка ашыру шартлары, фәнне үзләштерүнең нәтиҗәсен тикшерү һәм бәяләү.

**1.2. Фәннең һөнәри белем бирү төзелешендә тоткан урыны: <u>ОУД.11 Татар әдәбияты</u>**

Дисциплина гомуми гуманитар һәм социаль-экономик циклга керә һәм икенче курста өйрәнелә, курс дифференциаль зачёт белән тәгәлләнә.

**1.3.Фәннең максаты һәм бурычлары – әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

Югары сыйныфларда әдәбият укытуның төп **максатларын** исә түбәндәгеләр тәшкил итә:

-татар әдәбияты текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү; төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне **белү**; әдәби-тарихи процесс турында гомуми караш булдыру.

-укучыларда татар әдәбияты үзенчәлекләре турындагы карашларны, әдәби текстны кабул итү, автор позициясен аңлау, әдәби процессның тарихи һәм эстетик нигезләренә төшенү, образлы һәм аналитик фикерләү культурасын, эстетик һәм иҗади сәләтне, кызыксынуны үстерү.

-әдәби тел нормаларын саклап телдән һәм язма сөйләмнәрен **үстерү**.

-гомум әдәби-теоретик белемнәр нигезендә татар әдәбияты әсәрләренең тарихи-әдәби җирлеген аңлау һәм сәнгати кыйммәтен билгели белү; төрле типтагы язма эшләр башкару; кирәкле мәгълүматларны (татар телле Интернет челтәре аша, белешмә сүзлекләрдән, энөиклопедияләрдән) табу, системалаштыру һәм файдалану **күнекмәләре** булдыру;

-татар әдәбияты әсәрләрендә чагылыш тапкан гомум кешелек идеалларын рус әдәбияты әсәрләре белән үзара бәйләнештә аңлау һәм әдәби-сәнгати фикерләүдәге уртак һәм татар милләтенә хас үзенчәлекләрне күререгә өйрәтү.

-тиз үзгәрүчән заман шартларында файдалы җитештерүчән хезмәткә яраклы, үз-үзен танып белергә һәм һәрдаим камилләшергә әзер, гуманлы, рухи дөньясы бай шәхес тәрбияләү; гуманлылык карашлары, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, татар әдәбияты һәм мәдәни кыйммәтләренә кызыксыну һәм хөрмәт булдыру.

Өлкән сыйныфлардагы әдәбият курсына әдәби әсәрләрне **сайлап алуда төп таләпләр** булып аларның сәнгати кыйммәте, гуманистик эчтәлеге, укучы шәхесенә уңай йогынты ясавы, аның үсеш бурычларына һәм яшь үзенчәлекләренә туры килүе, милли рух белән сугарылуы, шулай ук мәдәни-тарихи традицияләргә һәм белем бирү тәҗрибәсенә нигезләнүе тора.

Тәкъдим ителә торган әдәби әсәрләр укучыларның гомуми төп белемнәренә нигезләнеп урнаштырыла. Өлкән сыйныфлардагы әдәбият курсы татар сүз сәнгатенең үсешен беркадәр күзаллауга һәм татар әдәбиятының классик әдәбиятта сәнгати, гомумкешелек кыйммәтләрен тулырак аңлауга юнәлтелә. Күрсәтелгән язучылар һәм әсәрләр исемлеген программа авторлары, тирәнтен өйрәнү максатыннан чыгып, киңәйтә ала.

Зур күләмле әсәрләрне кыскартып бирү, татар халкының милли үзенчәлекләре, традицияләре, гореф-гадәтләре киңрәк урын алган, милләтнең рухи-мәдәни асылы тулырак чагылган әсәрләрне анализлау; татар һәм рус әдәбиятларын чагыштырып өйрәнү рус телендә белем бирүче мәктәп үзенчәлекләрен исәпкә алып тәкъдим ителде.

Югары сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **гомуми нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыда әдәбиятны мөстәкыйль укып, аңларлык күнекмәләр булдыру;
- татар сүз сәнгатен рус һәм дөнья әдәбияты фонында кабул итәргә өйрәтү;
- татар әдәби теле нормаларын саклап язу һәм сөйләү күнекмәләре булдыру;
- кирәкле мәгълүмат һәм белемнәрне төрле чыганаклардан табу, алардан мөстәкыйль рәвештә кулланырга өйрәтү.

Югары сыйныфларда татар әдәбиятын укытуның **предмет нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

*Танып-белү өлкәсендә*:

- татарча әдәби текстны кабул итәргә һәм аңларга, иҗат ителгән чор белән тарихи-мәдәни бәйләнешләрен һәм аңа салынган мәңгелек кыйммәтләрне күзалларга өйрәтү;
- укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен беркадәр билгели, геройларын бәяли алуына ирешү;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларына кагылышлы төп фактларны белүенә ирешү;
- татар әдәбияты текстларын рус әдәбияты әсәрләре белән гомумкешелек кыйммәтләренә мөнәсәбәттә чагыштыру күнекмәләре формалаштыру;
- *бәяләү өлкәсендә*:
- татар әдәбиятына хас рухи-әхлакый кыйммәтләрне, әдәби-эстетик үзенчәлекләрне аңларга өйрәтү;
- мәдәниятара бәйләнешләрне саклау, укучының башка милләтләр мәдәнияте һәм әдәбиятыннан мәгълүматлы, башка халыкларның сүз сәнгатенә хөрмәтле мөнәсәбәттә, толерант булуына ирешү;
- баланың үзаңын үстерү, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- татар әдәбияты үрнәкләренә үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру.

*коммуникатив яктан*:

- татар әдәбияты әсәрләрен аңлап укый һәм кабул итә алуга ирешү;
- әдәби әсәрдәге вакыйгаларны һәм геройларны чагыштыру, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку, өйрәнелгән әсәргә бәйле телдән һәм язмача фикерләрне белдерергә өйрәтү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары аша эзләү күнекмәсе булдыру;
- укучының мөстәкыйль, иҗади фикерләвен активлаштыру;
- әдәби әсәрләр һәм ирекле темалар буенча татар телендә иҗади эшләр башкарырга өйрәтү.

*эстетик яктан*:

- әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен һәм милли үзенчәлекләрен тою хисе формалаштыру;
- баланың әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта әдәби һәм тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белүенә ирешү;
- рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү.

- **1.4. Тәрбия эше аша укучыларның шәхси нәтиҗәләрен формалаштыру:**
- Ш1 – Үзенне бөек илнең гражданины һәм таянычы итеп тану;
- Ш2 – Актив гражданлык позициясен чагылдыру, намуслылык, гаделлек приципларына таяну, икътисади активлык күрсәтү, территориаль һәм студентлар үзидарәсендә катнашу, шул исәптән, үз теләгең белән җәмәгать оешмалары белән хезмәттәшлек итү;
- Ш3 –Хокук тәртибе нормаларын саклау, гражданлык җәмгыяте идеалларына таяну, Россия гражданнарының куркынычсызлыгын, иреген һәм хокукларын тәэмин итү.

Субкультура вәкилләренә карата лояльлек күрсәтү, аларны тәртипләре деструктив һәм девиант булган төркемнәрдән аера белү; тирә-юньдәгеләрнең социаль яктан куркынычлы үз-үзләрен тотышларын кисәтү һәм кабул итмәү;

Ш4 – Хезмәт итүчеләрне хөрмәт итү, үз хезмәтеңнең кыйммәтен аңлау.Челтәрле мохитта шәхси һәм һөнәри конструктив “цифрлы эз» калдырырга омтылу;

Ш5 – Үз халкыңның мәдәниятен, тарихын, туган илеңне ярату, Россиянең күпмилләтле халкының традицияләрен кабул итү;

- Ш6 – Өлкән буын вәкилләренә карата хөрмәт күрсәтү, волонтерлар хәрәкәтендә катнашуга һәм социаль ярдәм күрсәтүгә әзер булу;
- Ш7 - Кеше шәхесенең өстенлекле кыйммәтен аңлау; төрле шартларда, эшчәнлекнең төрле формаларында һәм төрендә үзеңнең һәм чит кешеләрнең өстенлегенә хөрмәт белән карау;
- Ш8 - Этнокультур, социаль, конфессиональ һәм башка төркемнәргә хөрмәт белән карау. Күпмилләтле Россия дәүләтендә яшәүчеләрнең мәдәни традицияләрен саклауга, үстерүгә, күрсәтүгә өлеш кертү;
- Ш9 –Спортны, куркынычсыз һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау; азартлы уеннар, тәмәке, аракы эчүгә бәйлелекне кисәтү, яки аннан баш тарту. Катлаулы һәм тиз үзгәрүчән шартларда психологик тотрыклылыкны саклап калу;
- Ш11 – Мәдәниятнең эстетик нигезләрен белү, эстетик кыйммәтләргә хөрмәт белән кару;
- Ш12 –Гаилә кыйммәтләрен кабул итү, гаилә коруга һәм балалар тәрбияләүгә әзер булу; ата-ана җаваплылыгыннан, үз балаларың белән аралашудан һәм аларны матди яктан тәэмин итүдән баш тартуны, гаиләдә кул күтәрүне кабул итмәү.

**1. Фәнне өйрәнгәннән соң түбәндәге компетенция элементлары үзләштерелергә тиеш:**

ГК 01. Төрле контекстларга карата һөнәри эшчәнлек бурычларын хәл итү юлларын сайлау.

ГК 02.Профессиональ эшчәнлек бурычларын үтәү өчен кирәкле мәгълүматны эзләү, анализлау һәм интерпретацияләү.

ГК 03. Үз һөнәри һәм шәхси үсешеңне планлаштыру һәм гамәлгә ашыру.

ГК 04. Коллективта һәм командада эшләү, хезмәттәшләр, җитәкчелек, клиентлар белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итү

ГК 05. Социаль һәм мәдәни контекст үзенчәлекләрен исәпкә алып, дәүләт телендә телдән һәм язма коммуникацияләрне гамәлгә ашыру.

ГК 06. Гомумхалык әхлак кыйммәтләре нигезендә үзеңне аңлы рәвештә тоту, гражданлык позициясен күрсәтү.

ГК 07. Әйләнә-тирә мохитне, ресурсларны сакларга ярдәм итү, гадәттән тыш хәлләрдә нәтиҗәле эшләү.

ГК 08. Һөнәри эшчәнлек барышында сәламәтлекне саклау, ныгыту һәм тиешле физик әзерлек дәрәҗәсен саклап калу өчен физик культура чараларын куллану.

ГК 09. Профессиональ эшчәнлектә мәгълүмати технологияләрне куллану.

ГК 10. Дәүләт һәм чит телләрдә профессиональ документацияләрдән файдалану.

ГК 11. Һөнәри өлкәдә эшмәкәрлек эшчәнлеген планлаштыру.

ОУДНЫҢ уку дисциплинасын тәрбиянең түбәндәге шәхси нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә:

ЛР 2 актив гражданлык позициясен күрсәтүче, намуслылык, намуслылык, ачыклык принципларына тугрылык күрсәтүче, икътисади актив һәм студентлар һәм территориаль үзидарәдә, шул исәптән ирекле шартларда, нәтиҗәле хезмәттәшлек итүче һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлегендә катнашучы.

Лр 5 туган мәдәнияткә, туган илгә, туган халыкка, кече Ватанга мәхәббәт нигезендә тарихи хәтергә, Россиянең күпмилләтле халкының традицион кыйммәтләрен кабул итүгә тугрылыгын күрсәтә.

Лр 7 кеше шәхесенең өстенлекле кыйммәтен аңлаучы; төрле ситуацияләрдә, эшчәнлекнең барлык формаларында һәм төрләрендә үз һәм башкаларның уникальлеген хөрмәт итүче.

Лр 8 төрле этномәдәни, социаль, конфессиональ һәм башка төркем вәкилләренә хөрмәт күрсәтүче һәм күрсәтүче. Күпмилләтле Россия Дәүләтенең мәдәни традицияләрен һәм кыйммәтләрен саклау, арттыру һәм трансляцияләүдә катнаша.

Лр 11 эстетик кыйммәтләргә хөрмәт күрсәтүче, эстетик мәдәният нигезләренә ия.

ЛР 13 эш бирүчеләрнең өметләренә туры килергә әзер: актив, проект-фикерле, коллектив белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итүче һәм хезмәттәшлек итүче, профессиональ таләпләрне аңлы рәвештә үтәүче, җаваплы, пунктуаль, дисциплиналы, тырыш, тәнкыйди фикерле, һөнәри ныклык күрсәтүче.

ЛР 19 үз һөнәри үсеше белән идарә итүче, үз тормыш тәҗрибәсен, шәхси уңыш критерийларын рефлексив бәяләүче, өзлексез белем бирүнең кыйммәтен танучы.

**1.5 Фәнне үзләштерү өчен сәгатьләр саны:**

- максималь уку йөкләнеше: 117 сәгать;
- шул исәптән мәҗбүри аудитор уку йөкләнеше: 117 сәгать, в т.ч.ЛПЗ 20 ч. ;
- укучыларның үзлектән эше: 0 сәгать;

## 2. Уку фәненең төзелеше һәм эчтәлеге

Уку фәне: Татар әдәбияты

### 2.1. Укыту фәненең төрләре һәм саны

| **Укуның эш төрләре** | Сәгатьләр саны |
|---|---|
| **Укучының максималь уку йөкләнеше** | *117* |
| **Мәҗбүри аудитор уку йөкләнеше** | *78/39* |
| Шулай ук: | |
| Лаборатор эшләр | *-/-* |
| Практик эшләр | *20/-* |
| Курс эшләре | - |
| **Укучының үзлегеннән эше (барысы)** | *0* |
| Шулай ук: | |
| Укучынын курс эшләре буенча үзлегеннән эш | - |
| **Чыгарылыш нәтиҗәсе дифзачет** | |

**2.2.Уку программасыннның эчтәлеге һәм тематик планы Татар әдәбияты (первый год обучения)**

| Бүлекләр | Уку материалының эчтәлеге | Сәгать саны | Үзләш. дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| **1 нче бүлек Татар әдәбияты тарихына кереш** | | **2** | |
| тема 1.1 Татар әдәбияты тарихы | Татар әдәбияты тарихының чорларга бүленеше. | 2 | 2 |
| **2 нче бүлек Болгар чоры әдәбияты** | | **4** | |
| тема 2.1 **Болгар чоры әдәбияты** | Болгар чоры әдәбиятына күзәтү. | 2 | 2 |
| тема 2.2 Кол Гали “Кыссаи Йосыф” поэмасы | Кол Гали иҗаты һәм тормышы. “Кыссаи Йосыф” поэмасы, тарихы, композициясе. | 2 | 2 |
| | Самостоятельная работа | 0 | |
| **3 нче бүлек Алтын Урда чоры әдәбияты** | | **10** | |
| тема 3.1Алтын Урда чоры әдәбияты | Алтын Урда чоры әдәбиятына күзәтү. | 2 | 2 |
| тема 3.2 Алтын Урда чоры әдәбияты | Алтын Урда чоры әдәбиятына күзәтү, дастан турында төшенчә. | 2 | 2 |
| тема 3.3 Сәиф Сараи | Сәиф Сараи эшчәнлеге һәм тормышы. | 2 | 2 |
| тема 3.4“ Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастаны | “ Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастанының идея эчтәлеге<br>Практик эш. | 2 | 3 |
| тема 3.5“Идегәй” дастаны | “Идегәй” дастанының төп сюжеты. | 2 | 2 |
| | Самостоятельная работа | 0 | |
| **4 нче бүлек Казан ханлыгы чоры әдәбияты** | | **4** | |
| тема 4.1 Казан ханлыгы чоры әдәбияты | Казан ханлыгы тарихы һәм мәдәниятенә күзәтү. | 2 | 2 |
| тема 4.2Мөхәммәдъяр | Мөхәммәдъярның тормышы, иҗаты.“Нуры Содур”, “Төхфәи Мәрдан”поэмалары. | 2 | 2 |
| | Самостоятельная работа | 0 | |
| **5 нче бүлек XVII – XVIII йөз татар әдәбиятына күзәтү** | | **6** | |
| тема 5.1XVII йөз татар | XVII йөз әдәбияты. Мәүлә Колый “Хикмәтләр” | 2 | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| әдәбияты | | | |
| тема 5.2 XVIIIйөз татар әдәбияты | XVIII йөздә иҗат иткән әдипләр, татар әдәбиятында жанрлар | 2 | 2 |
| тема 5.3 Габдерәхим Утыз Имәни | Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты. Мәдхия һәм мәрсияләр. | 2 | 2 |
| | Самостоятельная работа | 0 | |
| **6 нчы бүлек XIX гасыр әдәбияты** | | **14** | |
| тема 6.1 XIX йөз әдәбияты | XIX йөз әдәбиятына һәм мәдәниятына күзәтү. | 2 | 1 |
| тема 6.2 XIX йөз әдәбияты | 19 нчы йөздә иҗат иткән күренекле әдипләр. | 2 | 2 |
| тема 6.3 Габделҗәббар Кандалый | Габделҗәббар Кандалыйның тормыш юлы, иҗаты. “Сәхибҗамалга” поэмасы | 2 | 2 |
| тема 6.4 Шиһабеддин Мәрҗәни | Шиһабеддин Мәрҗәни эшчәнлеге. Мәгърифәтчелек хәрәкәте | 2 | 2 |
| тема 6.5 Каюм Насыйри | Каюм Насыйри. Тормышы һәм купкырлы эшчәнлеге. | 2 | 1 |
| тема 6.6 Мифтахеддин Акмулла | Мифтахеддин Акмулланың тормыш юлы, иҗаты. | 2 | 2 |
| тема 6.7 Муса Акъегет | Муса Акъегет иҗаты. “Хисаметдин менла” романы. | 2 | 1 |
| | Самостоятельная работа | 0 | |
| **7 нче бүлек XX йөз башы әдәбиятына күзәтү** | | **38** | |
| тема 7.1 Гаяз Исхакый | Гаяз Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | 2 |
| тема 7.2“Ул әле өйләнмәгән иде” повесте | “Ул әле өйләнмәгән иде” повестенең сюжеты, композициясе Практик эш. | 2 | 3 |
| тема 7.3 Габдулла Тукай | Габдулла Тукай иҗаты һәм тормыш юлы. | 2 | 2 |
| тема 7.4 Габдулла Тукай | Габдулла Тукай әсәрләре. Практик эш. | 2 | 3 |
| тема 7.5 Дәрдемәнд | Дәрдемәнднең тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | 2 |
| тема 7.6 Сәгыйть Рәмиев | Сәгыйть Рәмиевның тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| тема 7.7<br>Г.Камал | Г.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты. “Банкрот” пьесасы.<br>Практик эш. | 2 | 3 |
| тема 7.8<br>Н.Җиһанов | Композитор Н.Җиһанов иҗаты. | 2 | 2 |
| тема 7.9<br>Бакый Урманче | Рәссам Бакый Урманче иҗаты. | 2 | 2 |
| тема 7.10<br>Габдулла Шамуков | Артист һәм язучы Габдулла Шамуков иҗаты. | 2 | 2 |
| тема 7.11<br>Фатих Әмирхан | Фатих Әмирханның тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | 2 |
| тема 7.12<br>Мирхәйдәр Фәйзи | Мирхәйдәр Фәйзинең тормыш юлы һәм иҗаты “Галиябану” драмасы<br>Практик эш. | 2 | 3 |
| тема 7.13<br>Шәехзадә Бабич | Шәехзадә Бабичның тормыш юлы һәм иҗаты. | 2 | 2 |
| тема 7.14<br>Шәехзадә Бабич | Шәехзадә Бабичның әсәрләренең идея-тематикасы. | 2 | 2 |
| тема 7.15<br>Сугыш чоры әдәбияты | Сугыш чоры әдәбиятына гомуми күзәтү, сугыш чорында иҗат иткән шагыйрьләр һәм язучылар. | 4 | 2 |
| Тема 7.16<br>Үзгәреш чоры әдәбияты | Үзгәреш чоры әдәбиятына гомуми күзәтү, үзгәреш чорында иҗат иткән шагыйрьләр һәм язучылар. | 4 | 2 |
| | Самостоятельная работа | 0 | |
| **Дифзачет** | | 2 | |
| | **Нәтиҗә** | **117** | |
| | | **-** | **-** |

**2.2.Уку программасынның эчтәлеге һәм тематик планы** **<u>Татар әдәбияты (второй год обучения)</u>**

| Бүлекләр | Уку материалының эчтәлеге | Сәгать саны | Үзләш. дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| **1 нче бүлек 20 нче еллар әдәбияты** | | **2** | |
| тема 1.1 2 0 нче еллар әдәбияты | Кәрим Тинчуринның тормышы һәм иҗаты.”Сүнгән йолдызлар”драмасы. | 2 | 2 |
| **2 нче бүлек 30 нчы еллар әдәбияты** | | **4** | |
| тема 2.1 30 нчы еллар әдәбияты | Гадел Кутуйның тормышы һәм иҗаты. “Тапшырылмаган хатлар”повесте. Практик эш. | 2 | 3 |
| | Гадел Кутуйның “Рөстәм мажаралары” әсәре. | 2 | 1 |
| | Самостоятельная работа | 4 | |
| **3 нче бүлек әдәбияты 40-50 нче еллар әдәбияты** | | **6** | |
| тема 3.1 Муса Җәлил | Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты. “Хуш, акыллым”, “Кошчык”, “Бүреләр” шигырьләре. “Тупчы анты” җыентыгы. “Моабит дәфтәрләре” җыентыгы. Практик эш. | 2 | 3 |
| тема 3.2 Муса Җәлил | Муса Җәлилнең “Моабит дәфтәрләре” җыентыгы. | 2 | 2 |
| тема 3.3 Фатих Кәрим | Фатих Кәримнең иҗаты һәм тормышы. “Сибәли дә сибәли “шигыре.”Разведчик язмалары” әсәре. | 2 | 2 |
| | Самостоятельная работа | 4 | |
| **4 нче бүлек 1960-2000 нче еллар әдәбияты (Поэзия)** | | **4** | |
| тема 4.1 Хәсән Туфан | Хәсән Туфанның тормышы һәм иҗаты. “Ә үткәнгә хатлар бармыйлар””Кайсы атта сиңа кайтып була?”, “Агыла да болыт агыла” шигырьләре. Практик эш. | 2 | 3 |
| тема 4.2 Сибгат Хәким | Сибгат Хәкимнең иҗаты һәм тормыш юлы. “Гел кояшка карый тәрәзәләрең”, “Башка берни дә кирәкми” шигырьләре. | 2 | 2 |
| | Самостоятельная работа | 4 | |
| **5 нче бүлек 1960-2000 нче еллар әдәбияты (Проза)** | | **12** | |
| тема 5. 1.Әмирхан Еники | Әмирхан Еникинең тормышы һәм иҗаты.”Матурлык” хикәясе. Практик эш. | 2 | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| тема 5. 2.Әмирхан Еники | Әмирхан Еникинең “ Әйтелмәгән васыять” хикәясе | 4 | 2 |
| тема 5.3 Мөхәммәт Мәһдиев | Мөхәммәт Мәһдиевнең тормышы һәм иҗаты. “41 нче ел балалары” повесте. | 4 | 2 |
| тема 5.4 Мөхәммәт Мәһдиев | Мөхәммәт Мәһдиев “ Бәхилләшү” повесте. | 2 | 2 |
| | Самостоятельная работа | 4 | |
| **6 нчы бүлек 1960-2000 нче еллар әдәбияты (Драматургия)** | | **6** | |
| тема 6.1 Хәй Вахит | Хәй Вахитның тормышы һәм иҗаты. “Беренче мәхәббәт “ драмасы.<br>Практик эш. | 2 | 3 |
| тема 6.2 Туфан Миңнуллин | Туфан Миңнуллинның тормышы һәм иҗаты. “Әлдермештән Әлмәндәр” драмасы. | 4 | 2 |
| **7 нче бүлек Балалар әдәбияты** | | **3** | |
| тема 7.1 Шәүкәт Галиев | Шәүкәт Галиевның тормыш юлы һәм иҗаты. “Урман күчә урамга”, “Багана”шигырьләре. Роберт Миңнуллин “Әни, мин көчек күрдем”, “Юкка малай булганмын”,”Без айга оча яздык” шигырьләре. | 3 | 2 |
| | Самостоятельная работа | 4 | |
| | **Нәтиҗә** | **37+24** | |
| **Дифзачет** | | **2** | **3** |

**3. Уку фәнен тормышка ашыру шартлары**

**3.1. Минималь материаль-техник тәэмин ителешкә таләпләр.**

Фән программасы тормышка ашыру кабинет булуны таләп итә: татар теле һәм әдәбияты кабинеты.

*Уку кабинетының җиһазлары:*

язу тактасы, кием шкафы, китап шкафы, өстәл (укучылар өчен), өстәл (укытучылар өчен), урындыклар, интерактив такта.

*Күрсәтмә пособиеләр*:

язучылар портретлары, алфавит, кагыйдәләр стенды, РФ һәм ТР президентлары портретлары.

**3.2.Укытуның информацион тәэмин ителеше**

**Әдәбият**

Укытучы өчен

1.Әдәбият.10 сыйныф:татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә. 1 нче кисәк./Ф.Ә. Ганиева, Д.М. Абдуллина, Ч.Р. Рамазанова.-Казан:Татар китап нәшрияты, 2016.-239 бит

2.Махмудов А.Г, Гараева Н.Г., Мухаметзянова Л.Ю. Татар әдәбияты= Татарская литература:Учебник – хрестоматия для студентов сред. спец. заведений.- Казань:Магариф, 2010.-631с.

3. Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыту программасы (рус балалары өчен): 1 – 11 сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2010. – 79б.

*Студентлар өчен*

1. Галиуллин К.Р.,Раскулова Р.И. Татар теленең орфографик сүзлеге.- Казан: Мәгариф,2010.-399 б.

2. Гарифуллин С.Ф. Татарча-русча-инглизчә сүзлек.- Казан: Татарстан Республикасы”ХӘТЕР” нәшрияты , 2010.-296 б.

**Интернет – чыганаклар**

1. Татар теле һәм әдәбияты — Википедия ru.wikipedia.org›wiki/Татар теле
2. Мин татарча сөйләшәм www.proshkolu.ru
3. Tatar.com.ru : татар теле
4. https://edu.tatar.ru
5. белем.ru

**4.Фәнне үзләштерүнең нәтиҗәсен тикшерү һәм бәяләү**

| Укыту нәтиҗәсе<br>( белергә, эшләргә тиеш) | Уку нәтиҗәләрен тикшерү һәм бәяләү формалары һәм алымнары |
|---|---|

| **Укучыларның үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:** татар әдәбиятының дөнья күләм тоткан урыны, татар әдәбияты классиклары, аларның әсәрләре ту рында мәгълүмат; сүз сәнгатенең образлы табигате турында; әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп факторы; төп әдәби – теоретик төшенчәләр; халык авыз иҗаты һәм әдәбият; татар әдәбияты тарихын чорларга бүлә белү; әдәби әсәрләрнең эчтәлеген һәм төзелешен (тема, идея, сюжет, композиция, образлар системасы һ.б.) анализлый белү; матур темадагы мәңгелек темалар, әдәбиятнын башка сәнгать төрләре белән бәйләнеше.<br>**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:** Текстның исеме, андагы таныш исемнәр ярдәмендә укучыларның эчтәлекне аңлаулары; укылган текст буенча әңгәмәдә катнаша алу;<br>өйрәнелгән язучылар турында сөйли белү;<br>укылган текстның эчтәлеген сөйли һәм нәтиҗә ясый белү, аңа үз мөнәсәбәтеңне белдерә алу; уку һәм сөйләм барышында орфоэпик нормаларны саклау;<br>балалар өчен басылган вакытлы матбугат материалларын уку һәм файдалана алу. | Изложение; инша; тестлар; реферат; эчтәлеген сөйләү; сорауларга җавап бирү; конспектлар төзү. |
|---|---|

**Якынча реферат темалары:**

1. Татар әдәбияты тарихы.
2. Алтын Урда чоры әдәбияты.
3. Казан ханлыгы чоры әдәбияты.
4. XVII – XVIII йөз татар әдәбиятына кузәтү.
5. XIX гасыр әдәбияты.
6. XX йөз башы әдәбиятына күзәтү.
7. 20-30 еллар әдәбиятына күзәтү.
8. 40-50 Еллар әдәбияты.
9. 60-90 нчы еллар әдәбиятына күзәтү.
10. Драматургия.